ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӨРЕШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БӨРЕШЛЕ АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

# КАРАР

06.04. 2024 ел № 2

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле
торак пунктында 2024 елда
гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының 2024 елның 26 мартындагы 1 номерлы 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында карары нигезендә

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Бөрешле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегенең Бөрешле авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә 1зм чарларны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Бөрешле авылында вак таш җәелгән юлларда чокырлы ремонтлау; Бөрешле авылында юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка

инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су өчен электр насослы скважина агрегаты сатып алу);

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасына янгын сүндерү җиңен алу);

4) торак пункт территориясен төзекләндерү (Бөрешле авылындагы территорияне чабу)

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында. www mendsleevsk.tatarstan.ru “Бөрешле авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Бөрешле авыл җирлеге башлыгы Л.А. Смирнова